| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2021 г.Лениногорск № 20

ТР «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 57 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. ТР «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 57 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 2 абзацында «милек характерындагы» сүзләреннән соң «шул исәптән цифрлы валюта турында мәгълүматлар» сүзләре белән тулыландырырга.

1 пунктның 3 абзацында «милек характерындагы» сүзләреннән соң «шул исәптән цифрлы валюта турында мәгълүматлар» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – «Лениногорские вести» газетында бастырырга, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов